ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 31 статьясына үзгәреш кертү хакында» 120-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 31 статьясына үзгәреш кертү хакында» 120-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 29 октябре
№ 433-VII ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 31 статьясына үзгәреш кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 31 статьясындагы 1 өлешенең $6^1$ пунктына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 79 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«$6^1$) дәүләт хезмәткәренең мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылуына, аның мобилизация буенча Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренә хезмәткә җибәрелүенә яисә аның тарафыннан мобилизация чорында, хәрби хәл чорында яисә сугыш вакытында хәрби хезмәт узу турында контракт йә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә яисә Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ихтыярый ярдәм күрсәтү хакында контракт төзелүгә бәйле рәвештә Федераль законның $53^1$ статьясында каралган гарантияләр;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 31 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 31 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 29 сентябрендәге 365-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә әзерләнде.

Федераль закон белән дәүләт хезмәткәрләренә аларның мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылуына, мобилизация буенча Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләренә хезмәткә җибәрелүенә яисә алар тарафыннан мобилизация чорында, хәрби хәл чорында яисә сугыш вакытында хәрби хезмәт узу турында контракт йә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә яисә Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ихтыярый ярдәм күрсәтү хакында контракт төзелүгә бәйле рәвештә бирелә торган гарантияләре төгәлләштерелде.

Закон проектында шундый ук үзгәрешләрне «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына кертү күздә тотыла. Аерым алганда, закон проектында каралган гарантияләр шулай ук мобилизация буенча Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренә хезмәткә җибәрелгән, шулай ук мобилизация чорында, хәрби хәл чорында яисә сугыш вакытында хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән дәүләт хезмәткәрләренә кагыла.

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 31 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 31 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 31 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 31 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә финанс чараларын бүлеп бирүне таләп итми.